Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе

Россия Мөфтиләр шурасы рәисе

بسم الله الرحمن الرحيم

# МӨФТИ ШӘЕХ РАВИЛ ГАЙНЕТДИННЕҢ ГАЙДЕЛ-ФИТР — УРАЗА ГАЕТЕ УҢАЕННАН МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

**Мәскәү**
Һижри 1441 елның 1 нче шәүвәле
Милади 2020 елның 24 нче мае

**БИСМИЛЛӘҺИР-
РАХМӘӘНИР-
РАХИИМ!**

**Рәхмәтле вә Рахимле Аллаһы Тәгалә
исеме белән башлыйм!**

Җирдә вә күкләрдә булган барча мәхлукат данлаган һәм бар нәрсәгә чиксез шәфәгате җиткән барча галәмнәрнең хуҗасы Аллаһу Сөбханәкә вә Тәгаләгә барча мактауларыбыз булса иде!

Соңгы Пәйгамбәребез, Аллаһының рәсүле Мөхәммәдﷺ гә, аның гаиләсенә, сәхәбәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр хак дин юлыннан аңа ияргән барчаларга салаватларыбыз булса иде!

**Хөрмәтле газиз дин кардәшләрем! Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!**

**Сезгә барчагызга да Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте ирешсен!**

Бүген Рамазан ае тәмамлануны белдергән изге бәйрәм — Гайдел-Фитр — Ураза гаете килеп җитте. Шуңа дөньяның барча мөселманнары чиксез хисләр — бар нәрсәне барлыкка китергән Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычыбызны янәдән үтәп чыгу шатлыгы кичерә. Раббыбызның Үзенең барлык илчеләренә тапшырылган күрсәтмәсе Аның һәрбер изге китапларында билгеләнгән һәм кешелек дөньясына җибәрелгән соңгы китабы — Коръәни Кәримдә әйткән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

***“Ий, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кеби, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз!”*** *(Коръәни Кәрим, 2:183).*

Рамазан ае дәвамында Аллаһу Тәгаләнең бездән ризалыгын өмет итеп, ураза тоттык, гыйбадәттә булдык, саваплы гамәлләр кылып, бердәм булырга омтылдык.

Бу санаулы һәм бәрәкәтле көннәрдә тәүлекнең якты вакытында без ашау-эчүдән генә түгел, көн саен изге китабыбыз Коръәни Кәримне укып, сүрәләрен яттан өйрәнеп, рухи яктан ныгыдык, әхлакый яктан камилләштек, начар фикерләрдән, сүзләрдән һәм гамәлләрдән дә тыелып тордык.

Һичшиксез, коронавирус пандемиясе Рамазан ае барышына сизелерлек үзгәрешләр кертте. Йогышлы авыруның куркынычын аңлап, без үз мәчетләребездә тәравих намазларын уку шатлыгыннан, туганнарыбыз һәм дусларыбызны чакырып, ифтар мәҗлесләре уздырудан баш тарттык.

Әмма Аллаһы Тәгалә безгә башка шатлык һәм юанычлар: гаиләләребез белән бергәләп ихлас догалар кылу мөмкинлеген, якыннарыбыз белән ашыкмыйча аралашу шатлыгын бирде, гәрчә башка вакытта дөнья мәшәкате белән якыннарыбызга игътибар күрсәтү өчен вакытыбыз җитмәгән булса да. Һәр дин тотучы мөселман өчен әйләнә-тирәдәгеләргә карата игелекле гамәлләр кылу, мәрхәмәтлек күрсәтү — ул иң зур шатлык.

Бу авыр көннәрдә килеп туган вәзгыять безне бер-беребездән аермады, без, киресенчә, берләшеп, нинди җенес һәм милләттән, нинди диндә һәм ничә яшьтә булуларына карамыйча, барча кешелеккә дә ярдәм итәргә өндәүче Ислам диненең матурлыгын күрсәттек. Бу хакта Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.):

والله في عَوْنِ العَبْدِ ما كَانَ العبدُ في عَوْنِ أَخِيهِ

***“...Кардәшенә булышып торган Үзенең яраткан бәндәсенә Аллаһы Тәгалә ярдәм итәчәк”*** *(Мөслим)*

Үзизоляция — өйләрдә бикләнеп тору кагыйдәсе кертелү сәбәпле, күп кенә дин кардәшләребезнең матди яктан авыр хәлдә калуын барыбыз да аңлый. Шул ук вакытта дин кардәшләребез арасында мохтаҗларга волонтер буларак ярдәм кулы сузучылар да аз булмады.

Күбебез ярдәмгә мохтаҗ булучыларга булышу йөзеннән үзенең милкеннән дә өлеш чыгарды. Изге Рамазан аенда ихластан һәм чиста ният белән кылынган гамәлләрне кабул итүен, фани дөньяда һәм ахирәттә аларның әҗер-савапларын күп мәртәбә арттыруын сорап, мин барча галәмнәрнең хуҗасы Аллаһы Тәгаләгә чын күңелдән догада торам.

Барыбызга да билгеле булганча, соңгы вакытларда коронавируска каршы көрәшнең алгы сызыгында — хастаханәләр. Табиблар, шәфкать туташлары, санитарлар, фельдшерлар — барлык медицина хезмәткәрләре профессиональ бурычларына тугры калып, минут саен гомерләрен куркыныч астына куялар. Догаларыбызда чын күңелдән Аллаһы Тәгаләдән аларны саклауны, Үзенең чиксез рәхмәте, мәрхәмәте белән ярлыкауны үтенәбез.

Без, әлбәттә, Аллаһыдан халкыбызны бу бәла-казадан саклавын, вирус йогышлы чир таралуга ирек куймавын, галимнәргә коронавируска каршы торуның нәтиҗәле чараларын уйлап табарга ярдәм итүен, кешеләрнең гомерләрен һәм сәламәтлеген саклап калуын сорап, Аңа бертуктаусыз гыйбадәт кылабыз. Тик шул ук вакытта барлык санитар күрсәтмәләрнең төгәл үтәлеше өчен үзебездән дә җаваплылыкны төшермибез.

Мәчетләребез һәм руханиларыбыз алга таба инфекция таралуны булдырмас өчен, кулдан килгәннең барысын да эшләделәр һәм, Аллаһыга шөкер, бу мәсьәләдә уңышка ирештек.

Шуңа күрә Гайдел-Фитр
бәйрәменең иң зур шатлыгы —
алдыңа куелган изге бурычны үтәп
чыгу, рухи чистарыну!

Һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) нең сөннәте буенча, әлеге айның ахыргы гамәле булып әл-фитра садакасын тапшыру санала. Нинди керемгә ия булуга карамастан, аны һәр мөселман кешесе түләргә тиеш.

فَرَضَ رَسُولُ اللهِ — صلى الله عليه وسلم — زَكَاةَ الفِطرِ طُهرَةً لِلصَّائِمِ
مِنَ اللَّغوِ وَالرَّفَثِ، وَطُعمَةً لِلمَسَاكِينِ

***“Аллаһының илчесе ураза тотучыларга буш һәм кирәкмәгән сүзләреннән чистарыну чарасы булган әл-фитраларын өләшергә һәм шул ук вакытта фәкыйрьләрне сыйларга боерды”*** *(“Сөнән”, Әбү Дауд).*

Барча дин кардәшләремне Рамазан аенда башланган әхлакый камилләшү юлын дәвам итәргә, изге гамәлләр һәм гыйбадәтләр кылып, Коръән аятьләрен укып, җангнарыбызны рухи азык ярдәмендә сугарырга, күркәмләндерергә өндим:

قَدْ أَفْلَحَ مَن تَزَكَّى وَذَكَرَ اسْمَ رَبِّهِ فَصَلَّى

***“Мөшриклектән вә монафикълыктан, рия вә бидгать гамәлләрдән, фәхеш вә хәрам эшләрдән үзен пакьләгән һәм сакланган кеше, тәхкыйк гәзабтан котылып, өстенлек тапты. Вә ул кеше Раббысына зикер итеп намаз укыды» (Коръәни Кәрим, 87: 14–15).***

**Кадерле ватандашларым, дин кардәшләрем!**

Россия Федерациясе мөселманнарының Диния нәзарәте һәм Россия Мөфтиләр шурасы исеменнән сезне чын күңелдән изге бәйрәм — Гайдел-Фитр (Ураза бәйрәме) белән котлыйм!

Аллаһы Тәгаләдән тоткан уразаларыбызны, укыган хәтем-догаларыбызны һәм изге эшләребезне кабул итеп, безгә Үзенең шәфкать-мәрхәмәтен бирүен сорыйм. Рамазан аеның уразасы барлык тән авыруларына һәм рухи авыруларга шифа булсын, иманыбызны ныгытсын, хәерсез гамәлләрдән чистартсын, хәләл белән файдалыдан тыелганны һәм зарарлыны аерырга өйрәтсен, күңелләребезне пакъласын.

Киләсе Рамазан айларын тынычлыкта һәм исәнлектә каршы алуыбызны сорап, Аллаһы Тәгаләгә дога кылам!

**Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ!**

***Мөфти шәех Равил Гайнетдин,***
*Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе*
*Россия Мөфтиләр шурасы рәисе*